# КЕРЕШ СҮЗ

Этнонимия – ономастиканың халык, кабилә һәм башка этник бергәлекләрнең атамаларын өйрәнә торган тармагы. Татар тел белемендә милләт атамалары бүгенгә кадәр аз тикшерелгән өлкәләрнең берсе дип әйтергә мөмкин. Татар лексикографиясендә укучы игътибарына тәкъдим ителә торган әлеге сүзлек – бу атамаларны туплап, системалаштырып биргән беренче белешмәлек.

Халыкларның төзелеше, төрле дәрәҗәдәге төркемнәре, бер-берсенә карата иерархик мөнәсәбәте төрле булган кебек, аларны белдергән этнонимнар системасы да шактый катлаулы. Сүзлеккә баш сүз итеп халыкларны, аларның эчендәге аерым этник группалар, этнографик төркемнәрне белдергән атамалар яки, киресенчә, аерым халыклардан торган зуррак бергәлекләрнең атамалары алынды. Ягъни сүзлеккә, *этноним* сүзенең иң киң мәгънәсен күздә тотып, халыкларның формалашуында катнашкан иң кечкенә берәмлекне белдергән *ыру* төшенчәсеннән башлап, халыкларның билгеле уртак үзлекләре нигезендә барлыкка килгән зур берләшмәләренең атамаларына кадәр кертелде. Шулай ук элек яшәгән, тарихта билгеле булган халыкларның, кабиләләрнең фәнни һәм популяр әдәбиятта очраган атамалары, хәзерге халыкларның иске атамалары да теркәлде. Сүзлек барлыгы 2 800 чамасы баш сүзне үз эченә ала. Төп игътибар Идел-Урал регионында яшәүче күрше халыкларны, Россиядә һәм башка дәүләтләрдә яшәүче тугандаш төрки халыкларны белдергән атамаларга юнәлтелде. Атамалары сүзлеккә кергән халыкларның гомуми географиясе исә бик киң.

Хәзерге вакытта дөньяда яшәгән барлык милләтләрнең төгәл саны билгеле түгел. Төрле чыганаклардагы мәгълү-

матларга караганда, бу сан 4500–6000 тирәсендә билгеләнә, Россиядә генә 180 милләт яши дип исәпләнә. Шуңа күрә объектив сәбәпләр белән сүзлек барлык халык атамаларын да колачлый алмый.

Төп сүз итеп милләтнең русча атамасы алынды. Һәр атаманың татарча варианты һәм аңлатмасы бирелде. Аңлатмада мөмкин кадәр кыска итеп халык турындагы мәгълүмат, бигрәк тә аны милләт буларак билгели торган иң әһәмиятле төп үзлекләре – теле, дине, яшәгән урыны, караган этник бергәлеге күрсәтелде.

Сүзлеккә кертү өчен берәмлекләр халык атамалары телгә алынган һәртөрле чыганактан җыелды. Беренче чиратта этнология, социология, тарих һ. б. тармакларга караган сүзлек, энциклопедия, фәнни һәм фәнни-популяр хезмәтләр, интернет челтәрендәге мәгълүмат тупланмалары, административ-территориаль берәмлекләрнең рәсми сайтлары, төрле халыкларның иҗтимагый һәм этно-мәдәни оешмаларының сайтлары, җыеп әйткәндә, гомуми куллану өчен ачык булган барлык чыганакларга мөрәҗәгать ителде. Аларның кайберләре әдәбият исемлегендә теркәлде.

Сүзлекне төзүдә очраган кыенлыкларның күпчелеге объектив проблемалар белән бәйле. Мәсәлән, фәнни әдәбиятта милләтнең статусы турында уртак фикер булмау, мөстәкыйль этносмы яки зуррак милләтнең бер үзенчәлекле төркемеме; телме яки диалектмы мәсьәләсе бәхәсле булу; әдәбиятта атамаларның вариантлары күплеге, шул исәптән ялгыш кулланылган вариантлар; милләтнең рәсми кабул ителгән атамасы, үзатамасы һәм аңа карата кулланылган экзоэтнонимнар арасындагы эзлексезлек кебек проблемаларны иң еш очраганнары буларак күрсәтергә мөмкин.

Вариантларга килгәндә, халык санын алу өчен әзерләнгән, шуларның нәтиҗәләренә нигезләнеп төзелгән, Россиянең милли составын чагылдырган рәсми исемлекләр кебек төрле чыганакларда бер үк халыкның берничә атамасы һәм варианты теркәлгән, шул исәптән хаталылары да. Аларның кайберләре

инглиз яки испан теленнән русчага ялгыш тәрҗемә ителгән, соңрак ул ялгыш татар теленә үтеп кергән. Милли атаманы рус теленә яраклаштырып транслитерацияләп язганда киткән ялгышлар да юк түгел. Андыйлардан котылырга тырышылды. Ләкин кайбер атамаларның фонетик һәм лексик вариантларын сүзлектә теркәү максатка ярашлы дип табылды. Әйтик, тарихның төрле чорларында төрлечә яңгыраган, төрле халыкларны белдергән, төрле авторларда яки төрле чыганакларда төрлечә теркәлгән күп кенә халык атамалары бар. Аларны кертү куллануучылар санын күбәйтә, сүзлекнең мәгълүматлылыгын арттыра, фәннилеген тәэмин итә торган өстәмә фактор дип саныйбыз.

Шулай ук милләтләрне белдергән атамалар арасында милләтне атауга кагылышы булмаган, яшәү урыныннан тыш бернинди үзенчәлекне белдермәгән **гомельчане / гомельлеләр, куалалумпурцы / куалалумпурлылар** кебек сүзләр очрый. Алар сүзлеккә алынмады, чөнки «Гомельдә яшәүчеләр», «Куала-Лумпурда яшәүчеләр» мәгънәсен генә белдерә, теләсә кайсы шәһәр, авыл исеменнән **казанлылар, минзәләлеләр, арчалылар** рәвешендә чиксез ясала алыр иде. Мәгънәсе белән бу атамаларга охшаш, шулай ук географик үзенчәлекне генә белдергән, милләт атамаларына кагылышы булмаган **евразийцы / евразиялеләр** «Евразия континентында яшәүчеләр», **латиноамериканцы / латинамериканнар** «Латин Америкасында, ягъни Америка континентының рәсми телләре латин теленнән килеп чыккан испан, португал, француз һ. б. телләр булган территорияләрендә яшәүчеләр» тибындагы атамалар да сүзлектә чагылдырылмады. Шулай да география белән бәйле атамалар сүзлектә бар. Алар, гадәттә, составы белән бердәй булмаган, күп һәм төрле милләтләрне берләштергән зур катнаш халыкларны (нацияләрне) белдерә, мәсәлән, **аргентинцы / аргентиналылар**, **ассамцы / ассамлылар** һ. б. Яки киресенчә, бер милләтнең дине, теле яки башка мөһим үзенчәлеге белән аерылып торган төркемен белдергән атамалар да алынды, мәсәлән, **тлядальцы / тлядаллылар**, **паланцы / паланалы-**

**лар** һ. б. Берәр төбәктә яшәүчеләрнең җирле кушаматы (мәсәлән, псковлыларга карата кулланылган *скобарь* сүзе һ. б.), дин үзенчәлегенә карата бирелгән атама (мәсәлән, *мормон* һ. б.), аерым милләтләргә карата негатив, ироник я башка төсмер белән кулланылган атамалар (мәсәлән, *азери, азер* һ. б.) да игътибарга алынмады, дөресрәге максатчан рәвештә анализланып төшереп калдырылды.

Сүзлек Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикография бүлегендә төзелде. Ул төрле тармак белгечләренең – этнологлар, социологлар, тәрҗемәчеләр, журналистлар, гомуми пландагы яки махсус тармак сүзлекләре, ике телле һ. б. сүзлекләр төзү белән шөгыльләнүче белгечләр, тел галимнәре, югары уку йортлары укытучылары, язучыларның кызыксынуын җәлеп итәр һәм гомумән киң катлау укучы өчен файдалы булыр дип көтелә.

Сүзлекне төзүдә түбәндәге авторлар катнашты: Ф. И. Таһирова – А, «Кереш сүз», «Сүзлекнең төзелеше турында»; Э. И. Сафина – Б – Й, С; И. И. Сабитова – К – Р; О. Н. Галимова – Т – Я.

Сүзлеккә кагылган тәкъдим һәм теләкләрне түбәндәге адреска җибәрергә мөмкин:

420111, Казан шәһ., К. Маркс ур., 12 йорт
Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты
Электрон адрес: iyali.anrt@mail.ru